ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**10.04.2023 ел**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1034**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә файдаланылган терекөмеш лампаларын туплау урыны (урыннары) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү хакында

1998 елның 24 июнендәге «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 89-ФЗ номерлы, 2002 елның 10 гыйнварындагы «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 7-ФЗ номерлы, 2009 елның 23 ноябрендәге «Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 261-ФЗ номерлы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 453-ТР Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге «Тиешенчә җыймау, тупламау, кулланмау, зарарсызландырмау, транспортламау һәм урнаштырмау гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зарар китерергә мөмкин булган яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында» 2314 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә Татарстан Республикасы, Зеленодольск шәһәре, Королев урамы, 24/1 адресы буенча файдаланылган терекөмеш лампаларын туплау урынын булдыруны оештырырга.
2. Күпфатирлы йортларда биналарның милекчеләре, яллаучылары, файдаланучылары булган терекөмешле лампалар кулланучылардан файдаланылган терекөмешле лампаларны туплау урыннары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары белән расланган, Тиешенчә җыймау, тупламау, кулланмау, зарарсызландырмау, транспортламау һәм урнаштырмау гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зарар китерергә мөмкин булган яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләренең 4 пункты нигезендә билгеләнә.
3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән файдаланылган терекөмешле лампаларны туплану урыннары, шул исәптән, күпфатирлы йортларда туплау урыннарын оештыру өчен бүлмәләр булмау сәбәпле, терекөмешле лампалар туплау

урыннарын оештыру мөмкин булмаган очракта, әлеге күпфатирлы йортлардагы биналар милекчеләре, яллаучылары, файдаланучылары булган терекөмешле лампалар кулланучылар өчен дә билгеләнгән дип гамәлгә кертергә.

4. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә файдаланылган терекөмеш лампаларын туплау урыны (урыннары) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат урнаштыру юлы белән хәбәр итәргә.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А. В. Старостин